**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 1 ноябрендәге 3801 номерлы карары**

**«Спорт – бердәм киңлек» проекты кысаларында**
**гражданнарның ташламалы категориясе исемлеген**
**раслау турында**

Муниципаль спорт учреждениеләре тарафыннан физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт хезмәтләрен күрсәткәндә гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 декабрендәге 1023 номерлы «“Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм” Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»гы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 3 октябрендәге 1219 номерлы, 2024 елның 19 февралендәге 89 номерлы, 2024 елның 10 апрелендәге 244 номерлы, 2024 елның 31 июлендәге 610 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән), Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 6 октябрендәге «“2024 – 2028 елларга Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерү” муниципаль программасын раслау турында»гы карары нигезендә Казан шәһәре территориясендә халыкка социаль ярдәм күрсәтү программасын гамәлгә ашыру максатыннан **карар бирәм**:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

1.1. Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән билгеләнгән категорияләрдән тыш, хезмәтләрдән файдаланучыларның аерым категорияләренә ташламалар билгеләү һәм ташламаларның күләме турында карар, финанс һәм матди-техник мөмкинлекләреннән чыгып, учреждение тарафыннан мөстәкыйль кабул ителә;

1.2. ташламалар билгеләү турында карар учреждение тарафыннан учреждение җитәкчесе әмере рәвешендә кабул ителә;

1.3. хезмәтләрдән файдаланучы бер үк вакытта берничә ташламалы категориягә караса, ташламалар, хезмәтләрдән файдаланучы теләгеннән чыгып, нигезләрнең берсе буенча билгеләнә;

1.4. билгеләнгән ташламалар турында мәгълүмат хезмәтләрдән файдаланучыларга аны учреждениенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, учреждение урнашкан яки хезмәт күрсәтелә торган биналардагы (бүлмәләрдәге) мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән җиткерелә.

2. «Спорт – бердәм киңлек» проекты кысаларында гражданнарның ташламалы категориясенең тәкъдим ителә торган исемлеген кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 21 октябрендәге 2744 номерлы «“Спорт – бердәм киңлек” гражданнарның ташламалы категориясе исемлеген раслау турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 1 ноябрендәге
3801 номерлы карарына
кушымта

## «Спорт – бердәм киңлек» проекты кысаларында гражданнарның ташламалы категориясенең тәкъдим ителә торган исемлеге

| Бирелә торган ташламалар | Гражданнар категориясе | Ташламалар алу өчен документлар | Хезмәт төрләре | Вакыты |
|---|---|---|---|---|
| Бушлай (тәкъдим ителә) | 1) Бөек Ватан сугышы ветераннары;<br>2) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;<br>3) реабилитацияләнгән затлар һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затлар;<br>4) I, II төркемгә караган инвалидлар;<br>5) инвалид балалар;<br>6) I төркемгә караган инвалидларны (хезмәт эшчәнлеген алып бару сәләте чикләнүнең III дәрәҗәсе) яки инвалид балаларны (I төркемгә караган һәр инвалидка яки инвалид балага (хезмәт эшчәнлеген алып бару сәләте чикләнүнең III дәрәҗәсе) бер озатып йөрүче зат) озатып йөрүче затлар;<br>7) мәгариф учреждениеләрендә белем алучы ятим балалар һәм ата-ана | 1) Шәхесне таныклый торган документ;<br>2) спортның билгеле бер төре белән шөгыльләнү өчен каршылыклар булмау турында медицина белешмәсе;<br>3) ташламалардан файдалану хокукын раслый торган документ | 1) Адаптив физик культура инструкторы дәресләр алып барган төркем күнекмәләренә атнага ике тапкыр йөрү (адаптив физик культура инструкторы булганда);<br>2) атнага ике тапкыр индивидуаль дәресләргә йөрү;<br>3) атнага ике тапкыр спорт мәйданчыкларын | 1) Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты белән килештерелгән очракта, спорт учреждениесе әмере белән раслана |

| Бирелә торган ташламалар | Гражданнар категориясе | Ташламалар алу өчен документлар | Хезмәт төрләре | Вакыты |
|---|---|---|---|---|
| | тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар;<br>8) ата-аналарның икесе дә I яки II төркемгә керүче инвалид булган гаиләдәге балалар;<br>9) Чернобыль атом электр станциясендәге һәлакәт, Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган затлар | | оештырылган төркемнәргә бирү буенча хезмәт күрсәтү (буш мәйданчыклар булган очракта) | |
| Ташламалы бәяләр буенча (түләүле хезмәт бәясенә 30% ташлама)<br>(тәкъдим ителә) | 1) Башлангыч һәм урта һөнәри белем бирә торган гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы, күп балалы аз керемле гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар (белем алу вакыты тәмамланганчы, ләкин унсигез яшькә җиткәнче);<br>2) сугыш һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары (Әфган конфликтында, Төньяк Кавказ төбәге территориясендә конституцион тәртипне саклау буенча чараларда һәм террорчылыкка каршы операциядә, махсус хәрби операциядә һ.б. катнашучылар);<br>3) III төркемгә караган инвалидлар; | 1) Шәхесне таныклый торган документ;<br>2) спортның билгеле бер төре белән шөгыльләнү өчен каршылыклар булмау турында медицина белешмәсе;<br>3) ташламалардан файдалану хокукын раслый торган документ | 1) Тренерсыз индивидуаль дәресләргә йөрү | 1) Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты белән килештерелгән очракта, спорт учреждениесе әмере белән раслана |

| Бирелә торган ташламалар | Гражданнар категориясе | Ташламалар алу өчен документлар | Хезмәт төрләре | Вакыты |
|---|---|---|---|---|
| | 4) картлык буенча эшләмәүче пенсионерлар;<br>5) хезмәт ветераннары;<br>6) «СССРның мактаулы доноры», «Россиянең мактаулы доноры» билгеләре белән бүләкләнгән затлар | | | |
| Ташламалы бәяләр буенча (түләүле хезмәт бәясенә 10% ташлама)<br>(тәкъдим ителә) | 1) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) алтын билгесе белән бүләкләнгән затлар | 1) Шәхесне таныклый торган документ;<br>2) спортның билгеле бер төре белән шөгыльләнү өчен каршылыклар булмау турында медицина белешмәсе;<br>3) ташламалардан файдалану хокукын раслый торган документ | 1) Тренерсыз индивидуаль дәресләргә йөрү | 1) Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты белән килештерелгән очракта, спорт учреждениесе әмере белән раслана |